Республика Татарстан

САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«29» май 2020 ел

№ 109

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче елларның план чорына салым чыгымнары исемлеген раслау

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2020 нче елның 6 апрелендә 76 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенең 2 нче пункты нигезендә, Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче еллар план чорына салым чыгымнары исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г. Гыйлманов

Саба муниципаль районы
Саба шәһәр башкарма
комитетының 29.05.2020 елгы
№109 карары белән расланган

**“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең 2020 нче елга һәм 2021, 2022 нче елларның план чорына салым чыгымнары исемлеге**

| Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый акты | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат ителүләрне һәм башка преференцияләрне бирү шартлары | Салым ташламалары, азат итү һәм башка преференцияләр каралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, азат ителүне һәм салымнар буенча башка преференцияләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән салым ташламаларына, азат итүгә һәм салымнар буенча бүтән преференцияләргә бирелгән хокукның гамәлдә булу датасы | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларының, азат ителүләренең һәм башка преференцияләрнең гамәлдә булу чоры | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламалары ның, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференция ләрнең гамәлдә булуын туктату датасы | Салым ташламалары ның, азат ителүләренең һәм салымнар буенча башка преференция ләрнең исеме | Салым чыгымнары ның максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаш тыручы яисә техник ташлама) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы тарафыннан 2019 нчы елның 3 нче апрелендә кабул ителгән 13 нче номерлы карар «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2014 нче елның 19 нчы | Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 18 яшькә кадәрге балаларны физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү | Өч һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүче 18 яшькә кадәрге балалар | 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап | 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап | Вакытсыз | Билгеләнмәгән | Тулы азат ителү | Халыкка социаль ярдәм |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ноябрендә кабул ителгән 44 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында» | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы тарафыннан 2019 нчы елның 28 нче ноябрендә кабул ителгән 43 нче номерлы карар «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Саба шәһәр җирлеге территориясендә җир салымы турында» | Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын җир салымыннан азат итү | Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары | 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап | 2020 елның 1 гыйнварыннан башлап | Вакытсыз | Билгеләнмәгән | Тулы азат ителү | Халыкка социаль ярдәм |